Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
СОВЕТЫ

# К А Р А Р

2020 елның 25 марты № 44/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2012 елның 13 декабрендәге 24/2 номерлы карары (2018 елның 13 декабрендәге 30/7 номерлы редакциясендә) белән расланган коррупцион хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.3 пунктын** түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

**2.3 пунктын** түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.3. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14_1, 15 һәм 27 статьяларында каралган түләтүләр муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәрнең вакытлы эшкә сәләтсезлеге, аның чираттагы ялда булу чорын исәпкә алмыйча һәм коррупциячел хокук бозу көненнән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше буенча башкару вакыты кертелми.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы

сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының законлылык һәм хокук тәртибен саклау буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров